КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 4 ноябрь г.Казань № 994

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында махсус сакланыла торган табигать территорияләре дәүләт реестрын раслау һәм махсус сакланыла торган табигать территорияләре мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 ел, 4 июль, 520 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында махсус сакланыла торган табигать территорияләре дәүләт реестрына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында махсус сакланыла торган табигать территорияләре дәүләт реестрын раслау һәм махсус сакланыла торган табигать территорияләре мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 ел, 24 июль, 520 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 24 март, 192 нче; 2011 ел, 13 май, 393 нче; 2011 ел, 26 июль, 604 нче; 2011 ел, 8 август, 641 нче; 2012 ел, 17 июль, 600 нче; 2013 ел, 27 март, 208 нче; 2013 ел, 1 июнь, 374 нче; 2013 ел, 6 июнь, 390 нчы; 2014 ел, 20 май, 335 нче; 2014 ел, 11 июнь, 399 нчы; 2014 ел, 17 октябрь, 767 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 904 нче; 2016 ел, 11 июль, 475 нче; 2016 ел, 21 июль, 493 нче; 2017 ел, 31 гыйнвар, 42 нче; 2017 ел, 30 сентябрь, 744 нче; 2018 ел, 12 февраль, 76 нчы; 2018 ел, 21 май, 380 нче; 2019 ел, 26 март, 221 нче; 2019 ел, 28 май, 445 нче; 2020 ел, 5 февраль, 77 нче; 2020 ел, 6 октябрь, 909 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә

алып) расланган Татарстан Республикасында махсус сакланала торган табигать территорияләре дәүләт реестрына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Аңлатма язуы» бүлегендә:

җиденче абзацта «188» саннарын «190» саннарына алыштырырга;


унберенче абзацта «144» һәм «79» саннарын шул ук эзлеклелектә «146» һәм «81» саннарына алыштырырга;

ундүртенче абзацта «464,667» саннарын «464,689» саннарына алыштырырга;

«Азнакай муниципаль районы» бүлегендә:

Азнакай муниципаль районының карта-схемасын һәм аңа бирелгән искәрмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Азнакай муниципаль районы





[4] – Ык елгасы
[5] – Эстәрле елгасы
[6] – Чатыртау
[7] – Владимировка сөзәклеге (Актүбә биләмәсе)
[209] – Мәнәвез үзәне»;

түбәндәге эчтәлекле «Мәнәвез үзәне [209]» бүлекчәсен өстәргә:

«Мәнәвез үзәне [209]

| | |
|---|---|
| Статусы | Төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле |
| Гамәлгә кую документлары | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 29 сентябрь, 881 нче карары |
| Урнашу урыны | Азнакай муниципаль районы, Мәнәвез авылы янында |
| Тикшерүдә тотучы дәүләт башкарма хакимият органы | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты |




Объектның тасвирнамәсе һәм аның әһәмияте. 9,7 гектар гомуми мәйданлы табигать һәйкәле Азнакай муниципаль районы, Мәнәвез авылы янында урнашкан.

Табигать һәйкәлен оештыру уникаль табигать ландшафтларын, биологик төрлелекне, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясының анда үсә һәм яши торган сирәк объектларын саклап калуга нигезләнә.


Бу территория хайваннар дөньясы объектларының (соры куян, дала көзәне, гади кыр тычканы, кече урман тычканы, җирән кыр тычканы, сары сиртмәкойрык, бүдәнә, үләт бөркете, кыр карчыгасы, дала карчыгасы, колаклы ябалак, йөнтәс аяклы ябалак, сары корташар, аполлон, төсен үзгәртүчән тал күбәләге), шул исәптән Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгәннәрнең яшәү урыны булып тора.

Саклау чаралары. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән табигать һәйкәлен саклау режимы нигезендә.».

«Лениногорск муниципаль районы» бүлегендә:

Лениногорск муниципаль районының карта-схемасын һәм аңа бирелгән искәрмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Лениногорск муниципаль районы





[20] – Дала Зәе елгасы
[21] – Шишмә елгасы
[170] – А.И.Щеповский исемендәге «Дала»
[210] – Покш Пандо»;

түбәндәге эчтәлекле « Покш Пандо [210]» бүлекчәсен өстәргә:

«Покш Пандо [210]

| | |
|---|---|
| Статусы | Төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле |
| Гамәлгә кую документлары | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 29 сентябрь, 881 нче карары |
| Урнашу урыны | Лениногорск муниципаль районы, Спиридоновка авылы янында |
| Тикшерүдә тотучы дәүләт башкарма хакимият органы | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты |




Объектның тасвирнамәсе һәм аның әһәмияте. 12,6 гектар гомуми мәйданлы табигать һәйкәле Лениногорск муниципаль районы, Спиридоновка авылы янында урнашкан.

Табигать һәйкәлен оештыру уникаль табигать ландшафтларын, биологик төрлелекне, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясының анда үсә һәм яши торган сирәк объектларын саклап калуга нигезләнә.

Бу территория үсемлекләрнең (матур кылган, каурый кылган һәм башка үсемлекләр) һәм хайваннарның (болын карчыгасы, гади торымтай) сирәк төрләре, шул исәптән Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгәннәрнең үсү һәм яшәү урыны булып тора. Табигать комплексы территориясендә Россия Федерациясенең Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән кошның сирәк төре – үләт бөркете очрый.

Саклау чаралары. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы закон-нарында билгеләнгән табигать һәйкәлен саклау режимы нигезендә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин